

Шәһәр vзәге буйлап барганда, еш кына электрон тәмәке тартып баручы яшvсмерне очратырга туры килә. Яшьләр арасында “вейпер”лар саны коннән-кон арта, дип борчыла белгечләр. Бик аяныч: сонгы елларда электрон тәмәке, гади кальяннар модага кереде. Янәсе, ул, гади тәмәкедән аерылмалы буларак, кеше организмы очен зарарсыз. Бу имеш-мимешкә ышанып, мода куучылар да кvп булды. Вейперлар кулында гади генә тәмәке тvгел, ә пар генераторы. Аны “вейп” (инглизчәдән vapour – “пар”) дип атап йортәләр. Биредә тәмәке vсемлеге урынына махсус сыекча, ягъни “жижка” кулланыла. Шуна кvрә ул янмый, ә пар бvлеп чыгара. Вейперлар шул парны сулый. Сыекча глицерин, пропиленгликоль, никотин кебек матдәләрдән тора. Заманча электрон тәмәке тартучылар арасында яшьләр генә тvгел, vсмерләр дә кvп, ди статистлар. Чонки парнын зыяны юк дип уйлыйлар.
Электрон тәмәке дә, гади тәмәке кебек vк, зарарлы икәне ачыкланган. Бу олкәдә галимнәр тәжрибә дә vткәреп олгергәннәр. 3D-принтердан кеше кvзәнәгендә булган биополимердан ясалма vпкә чыгарлыган. Ана, “vпкә”гә, электрон тәмәке пары жибәрелгән. Кvзәнәкләр тотен тәэсире кебек vк, зур зарар кvргән. Электрон тәмәке парында эретелгән химик катнашмалар житештерvчеләр рекламасындагы сыман зарарсыз тvгел икән. Ботендонья сәламәтлек саклау оешмасы мәгълvматларына караганда, электрон тәмәке “корбан”нары арасында vпкә шеше, йорәк-кан тамырлары авырулары килеп чыгу куркынычы бермә-бер арта. Пар ордерvчеләр янында тору, тәмәке тартучыларга караганда да куркынычрак, дип тә кисәткәннәр. Чонки һавага хром, никель кебек матдәләр бvленеп чыга.
Бер сәгать кальян тарту - берьюлы 20 тәмәкене тартып бетерvгә тин. Россиядә 50 миллион кеше тәмәке тарта. Ир-атларнын - 65, ә хатын-кызларнын 30 проценты тәмәке пыскыта.
Тиздән вейп һәм кальяннарны тәмәкегә тинләштерергә жыеналар. Монын турындагы закон Россия Дәvләт Думасынын тиздән кабул ителvе момкин. Россия Дәvләт Думасы депутаты Марат Бариев та тәмәке «газраиле»нә әйләнгән.
- Депутатлыкка кандидат сыйфатында очрашулар vткәргәндә, бик кvп кеше кальян кафеларына зарланып морәжәгать итте. Шушы мәсьәләне хәл итvгә алындым. Белгечләр әйткәнчә, кальян һәм, гомумән, тәмәке тарту наркологик авыруларга сәбәпче. Кальян тарту модасына аеруча яшьләр бирелде. Йозләрчә машиналарда жыелышып, кальян тарталар. Кальян һәм электрон сигаретлар тартуга чикләvләр кертv турында закон проекты әзерләдек. Хәзер ул проект Россия Хокvмәтенә бәяләмәгә тапшырылды. Хокvмәт бәяләмәсеннән сон, проектны шушы жәйдә vк Дәvләт Думасында карый башларбыз дип уйлыйм, - диде Марат Бариев.
Әлегә кадәр жәмәгать урыннарында электрон тәмәке тарту тыелмаган икән, димәк

рохсәт.
Киләчәк буын исән булсын иде.

**Н.Хәлил**